**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КОШКИ-НОВОТИМБАЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОШКИ-НОВОТИМБАЕВО АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422383 с. Кошки-Новотимбаево, ул. Писателей, 16

422383 Кошки-Новотимбаево авылы, Язучылар урамы, 16

тел. (84373) 52-6-31, факс 52-6-31, e-mail: Kntm.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559501, ИНН/КПП 1638001582/163801001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19 .06. 2024** **№ 36-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»2023 елның 16 июнендәге 27-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге Советы карар кылды:

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында " 2023 елның 16 июнендәге 27-1 номерлы карарының 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктчасы белән тулыландырырга:

8) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Җитәкче** **Н.П.Сапожников**